**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 7 августындагы 3276 номерлы карары**

**Мобиль кушымталар һәм**
**веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен**
**«Хакатон Kazan Digital Transformation»**
**Казан ачык конкурсын уздыру турында**

Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегендә цифрлы продуктлар куллануны популярлаштыру максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсенә (И.И.Сәлимҗанов) Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсын (алга таба – конкурс) оештыручы булып торырга.

2. Конкурс уздыру турында нигезләмәне әлеге карар кушымтасы нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 7 августындагы
3276 номерлы карарына
кушымта

**Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсын уздыру турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсын уздыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) 2024 елда Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсын (алга таба – конкурс) уздыру тәртибен, конкурста катнашучыларга һәм эшләргә таләпләрне, аларны тапшыру тәртибен, конкурс уздыру вакытларын җайга сала.

Конкурсны уздыруның төп максаты – Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегендә цифрлы продуктлар куллануны популярлаштыру.

Конкурсның төп бурычлары – шәһәр ресурслары белән идарә итү сыйфатын күтәрү, шәһәр мохитенең уңайлылыгын арттыру, Казан шәһәренең инновацион потенциалын арттыру, Казанда иминлек дәрәҗәсен күтәрү өчен цифрлы сервисларны модернизацияләү.

1.2. Конкурсны «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – «Казан шәһәренең Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» МКУ) оештыра.

Конкурс уздыру турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырыла.

1.3. Конкурс уздыру турындагы әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru), Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.kzn.ru) бастырып чыгару конкурсны игълан итү һәм анда катнашырга тәкъдим итү булып санала.

## II. Терминнар һәм билгеләмәләр

Катнашучы – конкурста катнашу өчен Нигезләмәнең V бүлеге кагыйдәләре нигезендә теркәлгән зат.

Ярыш биреме – командалар билгеләнгән вакыт эчендә үтәргә тиешле бирем.

Команда – ярыш биремен үтәү өчен берләшкән, 1 дән алып 5 кә кадәр кешедән торган катнашучылар төркеме. Һәр катнашучы бер команда составына гына керә ала.

Команда капитаны – команда исеменнән приз алырга һәм аны команда катнашучылары арасында бүләргә, шулай ук конкурс үткәрү барышында команда исеменнән оештыру карарларын кабул итәргә вәкаләтле, команда составыннан команда мәнфәгатьләрен яклау өчен сайланган катнашучы.

Эксперт – ярыш биременең социаль һәм (яисә) бизнес проблемаларының берсе буенча белемле зат. Конкрет юнәлештә биремне хәл иткәндә конкурста катнашучыларга мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтә.

Алып баручы – чараны уздыру өчен җәлеп ителә торган зат.

Проект – функционал турында мәгълүматны, дизайнны, команда тарафыннан ярыш биремен үтәү нәтиҗәсендә булдырылган һәм билгеләнгән вакытта жюри бәяләмәсенә тәкъдим ителгән беренчел кодны да кертеп, жюри тарафыннан бәяләү критерийларына туры килә торган мобиль кушымта, яки веб-сервис, яки мобиль кушымта яисә веб-сервис прототибы.

Конкурсның рәсми сайты – https://kazandigitallegends.com/kazan_digital_transformation адресы буенча урнаштырылган һәм конкурска турыдан-туры мөнәсәбәте булган актуаль мәгълүматны бастырып чыгару һәм чарада катнашуга гариза җибәрү өчен билгеләнгән мәгълүмати ресурс.

Модератор – оештыру комитеты составында булган, чараның барышы өчен җаваплы зат.

## III. Конкурсны уздыру урыны һәм вакытлары

3.1. Конкурс өч этапта үткәрелә:

3.1.1. Сайлап алу этабы: конкурста катнашу өчен командалар формалаштыру.

Гаризалар 2024 елның 5 августына кадәр (аны да кертеп) кабул ителә.

3.1.2. Конкурсның әзерлек этабы: катнашучылар командаларына конкурс тематикасы буенча мәгълүмат бирү, мәгълүмати электрон хатлар җибәрү юлы белән эшләү өчен эш инструментларыннан һәм видеодәресләрдән дистанцион файдалану мөмкинлеген тәэмин итү. Беренчел концепция һәм/яки проектны гамәлгә ашыру идеясен дә кертеп, командаларның конкурска мөстәкыйль әзерләнүе.

Уздыру вакытлары: 12.08.2024 - 23.08.2024.

3.1.3. Конкурсның төп (турыдан-туры катнашу) этабы түбәндәге чараларны үз эченә ала:

- конкурсны рәсми ачу тантанасы – 24.08.2024;
- конкурс мәйданчыгында, технологияләр кулланып, командаларның үз проектлары өстендә эшләве;
- булдырылган проектларны эксперт комиссиясе әгъзалары алдында яклау. Булдырылган проектларны яклау кысаларында Командаларга эшләнгән кушымтаны тәкъдим итәргә һәм аның эшен максатчан җайланмада күрсәтергә, проектны гамәлгә ашыру барышын тәкъдир итәргә һәм эксперт комиссиясе сорауларына җавап бирергә кирәк;
- конкурска нәтиҗәләр ясау (эксперт комиссиясе эше);
- конкурсның рәсми ябылу тантанасы һәм җиңүчеләрне бүләкләү.

Уздыру вакытлары: 24.08.2024 - 25.08.2024.

Уздыру урыны: Петербург урамы, 52.

3.2. Конкурсның аерым этапларын уздыру вакытлары, зарурлык булган очракта, оештыру комитеты карары буенча үзгәртелергә мөмкин. Мондый үзгәрешләр турында мәгълүмат, оештыру комитеты мондый үзгәрешләр турында карар кабул иткән вакыттан алып бер эш көненнән дә соңга калмыйча, конкурсның рәсми сайтларында бастырып чыгарыла.

## IV. Оештыру комитеты

4.1. Программаны эшләү һәм конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итү өчен оештыручылар «Казан шәһәренең Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» МКУ карамагындагы учреждениеләрнең вәкаләтле хезмәткәрләре арасыннан оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) төзиләр. Оештыручылар ихтыяры буенча Оештыру комитеты составына шулай ук коммерция оешмаларының һәм учреждениеләренең вәкаләтле вәкилләре дә кертелергә мөмкин.

4.2. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне башкара:

4.2.1. Конкурсны уздыру регламентын (алга таба – регламент) һәм конкурс программасын (алга таба – программа) әзерләүне, раслауны һәм Конкурста катнашучылар һәм барлык кызыксынган затлар игътибарына җиткерүне тәэмин итә.

4.2.2. Конкурста катнашучылар өчен конкурс биремнәрен һәм аларны бәяләү критерийларын эшләүне тәэмин итә.

4.2.3. Конкурсны әзерләү һәм уздыру процессын планлаштыруны һәм контрольдә тотуны тәэмин итә.

4.2.4. Эксперт комиссиясен һәм хисап комиссиясен формалаштыра һәм конкурсны әзерләү һәм уздыру чорында аларның эшен тәэмин итә.

4.2.5. Әлеге Нигезләмәгә каршы килми һәм конкурсны уңышлы оештыруга һәм уздыруга ярдәм итә торган, шулай ук аның нәтиҗәләре турында ачык мәгълүмат җиткерүче өстәмә оештыру-регламентлы карарлар кабул итә.

4.2.6. Мәгълүмати материаллар әзерләүне гамәлгә ашыра һәм конкурсны әзерләү һәм уздыру, шулай ук аның нәтиҗәләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә.

## V. Конкурс уздыру шартлары

5.1. Конкурста Россия Федерациясенең 14 яшьтән өлкәнрәк гражданнары, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм проект авторлары һәм (яисә) хокук ияләре булып торучы, әлеге Нигезләмә шартлары нигезендә смотр-конкурста катнашу өчен гариза һәм проект тәкъдим иткән «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы затлар (алга таба – катнашучылар) шәхсән үзләре һәм (яисә) иҗади коллектив составында катнаша ала.

Гаризаны шәхсән катнашу өчен биргән катнашучылар команда составына билгеләнәчәк.

5.2. Конкурста катнашу бушлай.

5.3. Конкурста теркәлү өчен конкурсның рәсми сайтында түбәндәге сылтама буенча гариза тутырырга кирәк: https://kazandigitallegends.com/kazan_digital_transformation.

5.3.1. Гариза формасы әлеге Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасы белән расланды.

5.4. Конкурста катнашу өчен мәҗбүри:

5.4.1. әлеге Нигезләмәнең 5.3 пунктында күрсәтелгән сылтама буенча кереп тутырыла торган шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү.

5.5. Гаризаны рәсмиләштерүгә таләпләр:

5.5.1. Гариза әлеге Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында күрсәтелгән форма буенча һәм таләпләр нигезендә тутырыла.

5.5.2. Командада катнашуга гариза команданың һәр катнашучысы тарафыннан аерым бирелә.

5.6. Гариза бирүче, гариза биргән вакыттан алып җиде көн эчендә үзе күрсәткән электрон почта адресына info@kazandigitalweek.com электрон почта адресыннан раслама алса, конкурста катнашу өчен теркәлгән дип санала.

## VI. Конкурсны уздыру тәртибе. Проектларны яклау

6.1. Конкурсның төп (турыдан-туры катнашу) этабы оештыру комитеты тарафыннан расланган һәм конкурсны оештыручыларның рәсми сайтында бастырылган регламент һәм конкурс программасы нигезендә үткәрелә.

6.2. Конкурсның төп (турыдан-туры катнашу) этабын үткәргәндә, катнашучылар өчен санитар-эпидемиологик таләпләр үтәлергә тиеш.

6.3. Регламент һәм конкурс программасы белән катнашучылар конкурсның рәсми сайтында таныша ала. Оештыручы регламентны һәм программаны берьяклы тәртиптә үзгәртү хокукына ия, шул ук вакытта әлеге үзгәрешләр конкурсның рәсми сайтында бастырылырга тиеш. Үзгәрешләр аларны конкурсның рәсми сайтында бастырганнан соң үз көченә керә.

6.4. Конкурсның турыдан-туры катнашу этабы барышында командалар проект рәвешендә, шул исәптән үтәли цифрлы технологияләр һәм ачык мәгълүматлар кулланып, конкурс биремен башкаралар.

6.5. Проект турыдан-туры катнашу этабы вакытында эшләнгән булырга һәм алданрак гамәлдә булган, конкурс уздырганчы эшләнгән программа продуктын үстерү булып тормаска тиеш.

6.6. Команда эксперт комиссиясенең эшләнгән проектын тәкъдим итәргә тиеш. Бер команда бер генә проект тәкъдим итәргә хокуклы.

6.7. Проект өстендә эшләр тәмамлангач, команда эксперт комиссиясенә бәяләү өчен түбәндәге материалларны тәкъдим итә:

- эшләнгән проект һәм проект ресурслары белән папка;
- экспортланган (җыелган) мобиль яисә веб-кушымта;
- концепция (идеяләр), эшләп чыгару барышы турында мәгълүмат һәм нәтиҗәләрне анализлау белән проектны тәкъдир итү.

6.8. Команда тарафыннан барлык материаллар цифрлы матди чыганакта 1 данәдә бирелә.

6.9. Проектларны яклау форматы: презентация материалларыннан файдаланып, үз проектыңны монолог рәвешендә тасвирлау һәм булдырылган кушымта эшен эксперт комиссиясе әгъзаларына күрсәтү. Бер команда өчен чыгыш ясау вакыты 7 минуттан артмаска тиеш.

6.10. Эксперт комиссиясе әгъзаларының сорауларына җавап бирү өчен һәр командага өстәмә вакыт бирелә. Эксперт комиссиясе проектларны яклау барышында командалардагы катнашучыларга ачыклык кертә торган сораулар бирә.

6.11. Модератор командаларның чыгыш ясау вакытын җайга сала. Модератор, Нигезләмәнең 6.9, 6.10 пунктларында күрсәтелгән билгеләнгән вакыт узганнан соң, чыгыш ясаучыларны туктатырга хокуклы.

6.12. Нәтиҗәләр ясау һәм җиңүчеләрне һәм бүләкләнүчеләрне бүләкләү чараның ябылу тантанасы кысаларында конкурсның төп этабын үткәрүнең соңгы көнендә уздырыла.

## VII. Конкурс биремнәренә таләпләр һәм тәкъдимнәр

7.1. Конкурс биремнәре әзерлекнең төрле дәрәҗәләрендә катнашучылар өчен төрле катлаулыкларга туры килергә мөмкин.

7.2. Конкурс биремнәре, әгәр регламентта башкача каралмаган булса, төп (турыдан-туры катнашу) этап башланыр алдыннан игълан ителә.

7.3. Команда составына кермәгән өченче затлар тарафыннан конкурс биремен үтәү рөхсәт ителми.

7.4. Конкурс биремен үтәгәндә, Интернет челтәреннән файдаланырга рөхсәт ителә.

## VIII. Конкурсның эксперт һәм хисап комиссиясе

8.1. Конкурста катнашучылар эшләгән проектларны тикшерү һәм бәяләү өчен Оештыру комитеты кимендә өч кешедән торган эксперт комиссиясен төзи.

8.2. Эксперт комиссиясе составы конкурсны оештыручы тарафыннан билгеләнә.

8.3. Эксперт советы конкурсның сайлап куелган һәм ачык органы булып тора, халыкның ышанычын, конкурсның статусын һәм абруен тәэмин итә.

8.4. Эксперт комиссиясен формалаштыруның төп принцибы – аның составына 3D-модельләштерү һәм арт-технологияләр өлкәсендә тематик һәм конкурс биремнәре өлкәсендә компетентлы белгечләрне кертү мөмкинлеге, шулай ук федераль һәм төбәк дәүләт хакимияте органнары, төрле ведомстволар, фән һәм мәгариф, бизнес-бергәлекләр, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен,

экспертларны һәм белемнең төрле өлкәләрендәге белгечләрне җәлеп итү мөмкинлеге.

8.5. Эксперт эшчәнлеге фикернең бәйсезлеге, профессиональлек һәм бәяләү буенча компетентлык, гадел бәяләмә бирү принципларына нигезләнергә тиеш.

8.6. Эксперт комиссиясе түбәндәге функцияләрне башкара:

- контроль һәм нәтиҗәләр ясау;
- проектлар буенча балларда бирелгән эксперт бәяләмәсе;
- конкурста җиңүчеләрне һәм бүләкләнүчеләрне билгеләү.

8.7. Конкурста җиңүчеләр турындагы мәсьәләне карап тикшергәндә, эксперт комиссиясе бәяләмәсе иң күп бал җыйган катнашучы файдасына кабул ителә.

8.8. Кызыксынучы затларның эксперт төркеме эшендә катнашырга хокукы юк.

8.9. Экспертиза уздырганда, эксперт советы әгъзалары бурычлы:

- катнашучылар тапшырган материалларга аларның критерийларга туры килүе буенча анализ ясарга;
- һәр критерий буенча балларны күрсәтеп, команданың бәяләү формасын һәм нәтиҗәләр буенча бәяләү формасын тутырырга;
- экспертка конкурста катнашучы яки катнашучылар белән билгеле бер финанс яисә башка мәнфәгатьләр буенча бәйле булган команданы бәяләү кирәк булган очракта, конкурсны оештыручыга эшне бәяләүдән баш тарту турында җиткерергә.

8.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе карары беркетмә белән 1 эш көненнән дә соңга калмыйча рәсмиләштерелә һәм Оештыру комитетына тапшырыла.

8.11. Командаларга шобага салу, конкурста катнашучылар җыйган балларны санауны оештыру, конкурс нәтиҗәләре буенча җыелма бәяләү ведомостьларын әзерләү өчен хисап комиссиясе төзелә, аның составы Оештыру комитеты тарафыннан 2024 елның 24 августыннан да соңга калмыйча раслана.

8.12. Конкурс экспертлары әлеге нигезләмәгә 2 номерлы кушымта нигезендәге бәяләү критерийлары буенча конкурс чыгышларын бәяләүне гамәлгә ашыра.

8.13. Эксперт комиссиясе әгъзаларының бәяләү кәгазьләре, җыелма бәяләү ведомостьлары һәм беркетмәләр бастырып чыгарылырга, конкурста катнашучыларга һәм башка өченче затларга тапшырылырга тиеш түгел.

8.14. Конкурс проектларын бәяләү нәтиҗәләре буенча апелляцияләр кабул ителми.

## IX. Конкурска нәтиҗә ясау тәртибе

9.1. Проектларны бәяләү нәтиҗәләре буенча эксперт һәм хисап комиссиясе иң күп балл җыйган иң яхшы проектларны сайлап ала. Конкурста катнашучылар арасыннан әлеге проектлар авторлары конкурсны оештыручылар тарафыннан дәрәҗәләр нигезендә дипломнар белән бүләкләнәләр:

- 1 нче урын – 1 нче дәрәҗәдәге диплом (югары дәрәҗә – җиңүче) – 400 000 сум;
- 2 нче урын – 2 нче дәрәҗәдәге диплом (бүләкләнүче дипломы) – 250 000 сум;
- 3 нче урын – 3 нче дәрәҗәдәге диплом (бүләкләнүче дипломы) – 150 000 сум.

9.2. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат Интернет челтәрендә конкурсның рәсми сайтында урнаштырыла.

9.3. Җиңүчеләр дип танылган командалар капитаннары, җиңүчеләр турында мәгълүмат конкурсның рәсми сайтында урнаштырылганнан соң, 30 календарь көн эчендә бүләкне алу өчен оештыручылар белән элемтәгә керергә һәм конкурсны оештыручыларга моның өчен кирәкле барлык мәгълүматларны тапшырырга тиеш:

паспорт яисә шәхесне таныклый торган башка документ күчермәсен;

физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

законлы вәкилнең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын (кирәк булганда);

акчалата бүләк күчерелергә тиешле банк счеты реквизитларын.

Конкурсның рәсми сайтында җиңүчеләр турында мәгълүмат урнаштырылганнан соң, 30 календарь көн эчендә команда капитаны оештыручылар белән элемтәгә кермәсә һәм/яки бүләкне алу Нигезләмәнең 9.3 пунктында санап үтелгән барлык кирәкле мәгълүматларны/документларны өчен тапшырмаса, бу җиңүче бүләк алудан баш тарткан дип саналачак.

9.4. Җиңүчене бүләкләү команда капитаны тарафыннан Нигезләмәнең 9.3 пунктында санап кителгән барлык мәгълүматларны/документларны тапшырган көннән алып 30 эш көне эчендә башкарыла.

9.5. Конкурста җиңүче, бүләк алгач, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормалары нигезендә барлык салымнарны, җыемнарны һәм

түләүләрне мөстәкыйль рәвештә үзе түли, шул ук вакытта физик затка бирелгән бүләк суммасыннан Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нормалары нигезендә физик затлар кеременә салым тотып калына.

9.6. Конкурсны оештыручылар һәм оештыруда катнашучылар командада катнашучылар арасында бүләкне бүлешү өчен җаваплы түгел. Бүләк командада катнашучылар арасында, үзара килешеп, мөстәкыйль бүленә, конкурсны оештыручылар һәм оештыруда катнашучылар бу эштә катнашмый.

9.7. Конкурс нәтиҗәләре, конкурска нәтиҗәләр чыгарылганнан соң бер көннән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) урнаштырыла. Конкурсны оештыручы гаризада күрсәтелгән элемтә мәгълүматлары буенча җиңүчеләргә һәм бүләкләнүчеләргә мәгълүматны җиткерә.

## X. Конкурсны оештыручының хокуклары һәм бурычлары

Конкурсны оештыручы:

- конкурста катнашу өчен җибәрелгән гаризаларны һәм башка мәгълүматны рәсмиләштерүнең дөреслеген, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән шартларга туры килүен тикшерә;
- катнашучылардан әлеге Нигезләмәнең үтәлешен таләп итә;
- документларны тикшерә һәм гаризаны тулысынча тутырмаган, үз гаризасын билгеләнгән вакыттан соңрак җибәргән (әлеге Нигезләмәнең III бүлеге) яисә әлеге Нигезләмәнең V бүлегендә күрсәтелгән документларны тапшырмаган (тулы күләмдә тапшырмаган) катнашучыны кире кага;
- әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда конкурсны үткәрә;
- эксперт комиссиясен матди-техник яктан тәэмин итә, эксперт комиссиясе утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә.

Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсын уздыру турындагы нигезләмәгә 1 номерлы кушымта
(форма)

«Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» башлыгы

**Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсында катнашуга гариза формасы**

| | |
|---|---|
| Фамилия* | |
| Исеме* | |
| Атасының исеме | |
| Туу датасы* | |
| Элемтә өчен телефон номеры* | |
| Электрон почта* | |
| Ил* | |
| Телеграммга сылтама* | |
| Конкурста катнашучы эшли/белем ала торган компания/югары уку йорты исеме* | |
| Катнашучы командада нинди рольне алырга әзер?** | |
| Ит-продуктлар эшләүдәге тәҗрибәсе?** | |
| Хакатоннарда катнашу тәҗрибәсе?** | |
| Команда атамасы*** | |
| Сайланган бурыч** | |

Конкурста катнашуга гариза конкурсның рәсми сайтында бирелә.

*Мәҗбүри тутырылырга тиешле юл
** Рәсми сайттагы гаризада тәкъдим ителгән сайлау вариантлары нигезендә күрсәтелә
*** Команда составында гариза биргәндә күрсәтелә, шәхсән үзе өчен катнашканда, әлеге юл тутырылмый

Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсын уздыру турындагы нигезләмәгә 2 номерлы кушымта
(форма)

«Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе» башлыгы

## Мобиль кушымталар һәм веб-сервислар эшләп чыгаручылар өчен «Хакатон Kazan Digital Transformation» Казан ачык конкурсында катнашучылар проектларын бәяләү критерийлары

| Команда | | Проект исеме | Тәкъдим ителгән карарның кейста куелган бурычка туры килүе | Карар концепциясенең, продуктның алга таба үсешен күзаллауның уйлап эшләнгән булуы | Сайланган кейс кысаларында проектның кулланылышы перспективасы | Тәкъдим ителә торган карарның инновацияле һәм яңа булуы | Тәкъдим ителә торган карардан файдалануның уңайлылыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы | Презентация үткәрүнең сыйфаты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 1-5 диапазонында бәя куегыз, биреддә 1 - критерийга бөтенләй туры килми, 5 - критерийга 100 процент (яки якынча) туры килә | | | | | |
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |
| Эксперт (фамилиясе, исеме, атасының исеме) | | | | | | | | |